# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлегенең Чуаш Шәпкәсе авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

## КАРАР

2019 елның 26 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 20 номерлы Әлки муниципаль районының «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 19 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Шәпкәсе авылы торак пунктында гражданнар җыенының 2019 елның 11 ноябрендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге составына керүче Чуаш Шәпкәсе авылындагы гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме: алардан:

-суэтем челтәрләрен реконструкцияләү һәм су белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру буенча проект-смета эшләре башкару, урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, су башнялары территорияләрен коймалау һәм буяу, лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-110;

-урам утларын урнаштыруга кирәкле материал (яктырткычлар) сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтажлау эшләре һәм урамнарны яктырту өчен кулланылган энергия чыгымнарына түләү-100 сум;

-җирлек эчендәге юллар һәм урамнарны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, торак пункт эчендәге юллар һәм урамнарны чабу, юлларны грейдерлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистарту), МТЗ-80 тракторына хезмәт күрсәтү, тракторчыга килешү буенча түләү, тракторга ягулык-майлау материаллары сатып алу-305 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерлар сатып алу, белгечләргә килешү буенча түләү-85 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

-суэтем челтәрләрен реконструкцияләү һәм су белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру буенча проект-смета эшләре башкару, урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, су башнялары территорияләрен коймалау һәм буяу, лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-110;

-урам утларын урнаштыруга кирәкле материал (яктырткычлар) сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтажлау эшләре һәм урамнарны яктырту өчен кулланылган энергия чыгымнарына түләү-100 сум;

җирлек эчендәге юллар һәм урамнарны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, торак пункт эчендәге юллар һәм урамнарны чабу, юлларны грейдерлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистарту), МТЗ-80 тракторына хезмәт күрсәтү, тракторчыга килешү буенча түләү, тракторга ягулык-майлау материаллары сатып алу-305 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерлар сатып алу, белгечләргә килешү буенча түләү-85 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Матак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Иске Матак авыл җирлеге башлыгы: Н.И. Кудряшов